КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль

г.Казань

№ 172

Химик көнен бәйрәм итү турында

Татарстан Республикасының икътисадый потенциалын формалаштыруда һәм үстерүдә химия һәм нефть химиясе сәнәгатенең ролен һәм әһәмиятен исәпкә алып, халыкның киң катлаулары арасында фән казанышларын популярлаштыру һәм аларны җитештерүгә кертү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Ел саен май аеның өченче декадасында Түбән Кам шәһәрендә нефть-газ-химия комплексы предприятиеләре, мәгариф оешмаларында укучылар һәм педагогик хезмәткәрләр, тармак институтлары вәкилләре, шулай ук предприятиеләр ветераннары һәм «Россия Федерациясе Атказанган химигы» һәм «Татарстан Республикасы Атказанган химигы» мактаулы исемнәренә лаек булган затлар катнашында Химиклар көнен бәйрәм итүгә багышланган тантаналы мәдәни-массакүләм чаралар уздырыла дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасында Химик көнен бәйрәм итүгә багышланган тантаналы һәм мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба - Чараның оештыру комитеты) төзергә һәм аның кушымта итеп бирелә торган составын расларга.

3. Чараның оештыру комитетына күрсәтелгән чараларны әзерләү һәм уздыру эшен яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралу шартларында профилактик чараларны үтәүне тәэмин итә торган рәвештә оештырырга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына үтәргә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетына, «Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ, «СИБУР Холдинг» ГАҖ, «ТАИФ» АҖ, «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, «Казаньоргсинтез» ГАҖ, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә, нефть-газ химиясе комплексы

предприятиеләренә һәм оешмаларына чаралар әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына чараларны үткәрү урыннарында аларны оештыручыларга хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

7. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химиклар көнен бәйрәм итү турында» 2011 ел, 15 июнь, 481 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химиклар көнен бәйрәм итү турында» 2011 ел, 15 июнь, 481 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 01июнь, 375 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче карарына 2 нче кушымтаның 4 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2015 ел, 21 декабрь, 962 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2016 ел, 21 декабрь, 963 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2017 ел, 27 декабрь, 1061 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2018 ел, 12 декабрь, 1113 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 ел, 08 декабрь, 1105 нче карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан

Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарына 2 нче кушымтаның 3 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 19 май, 903-б номерлы боерыгы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль,172 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасында Химик көнен бәйрәм итүгә багышланган тантаналы һәм мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Минсадыйров Ирек Илдар улы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының химия һәм газ химиясе бүлеге башлыгы, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Ильин Алексей Леонидович | Сәнәгатьнең химия тармаклары хезмәткәрләренең Россия һөнәри берлеге иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Казаков Юрий Михайлович | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Лаврентьев Александр Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Муллин Рамил Хәмзә улы | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Савельчев Алексей Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Таюрский Дмитрий Альбертович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шахов Алексей Алексеевич | «СИБУР» ҖЧҖ директоры (дәүләт органнары белән элемтә, булу төбәкләренең социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итү) (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль,172 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасында Химик көнен бәйрәм итүгә багышланган тантаналы һәм мәдәни-массакүләм чаралар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Минсадыйров Ирек Илдар улы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының химия һәм газ химиясе бүлеге башлыгы, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Ильин Алексей Леонидович | Сәнәгатьнең химия тармаклары хезмәткәрләренең Россия һөнәри берлеге иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Казаков Юрий Михайлович | югары белем бирүче «Казан илкүләм тикшеренү технологик университеты» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Лаврентьев Александр Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Муллин Рамил Хәмзә улы | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Савельчев Алексей Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Айрат Фоат улы | «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Таюрский Дмитрий Альбертович | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шахов Алексей Алексеевич | «СИБУР» ҖЧҖ директоры (дәүләт органнары белән элемтә, булу төбәкләренең социаль-икътисадый үсешенә ярдәм итү) (килешү буенча) |
| Яруллин Рафинат Самат улы | «Татнефтехиминвестхолдинг» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |